Уставка үзгәрешләр теркәлде
Россия Федерациясе Юстиция
Министрлыгының Татарстан
Республикасы буенча идарәсе
«11» август 2020 ел
Дәүләт теркәү
№ RU165301172020002


РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 июля 2020 года № 47

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 94, 95, 96 статьялары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен игътибарга алып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары (Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 3 номерлы, 2018 елның 16 маендагы 21 номерлы, 2019 елның 13 февралендәге 5 номерлы, 2020 елның 21 февралендәге 12 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Түбән Кама шәһәре Мэрына (А.Р. Метшин) әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2020 елның 13 июле
47 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Шәһәрнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы» 8 статьясында 1 нче кисәктә «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы ассоциациясе» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Шәһәр Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләп торучы башка зат статусы» 32 статьясында:

а) 2 нче кисәктә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «шәһәр Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыру өчен, айга ике эш көне чорында эш урынын (вазыйфаларны) саклау гарантияләнә.»;

б) 6 нчы кисәкнең 2 нче пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер – министры) билгеләгән тәртиптә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

3. «Шәһәр Мэры урынбасарлары» 47 статьясында 5 нче кисәкне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5. Шәһәр Мэры шәһәр Советына азат ителгән нигездә ике урынбасар һәм азат ителмәгән нигездә ике урынбасар сайларга тәкъдим итәргә хокуклы.».

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары И.Н. Нуретдинов